**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ
РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

“15” май 2024ел. №228

**“Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының депутатлары, сайланган вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында” 2022 елның 29 мартындагы 120 номерлы Әтнә район Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елдагы №131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 елдагы №25-ФЗ Федераль закон, 25.06.2013 елдагы № 50-ТРЗ Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турында кодексы, “Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнары рәисләренә, Рәис урынбасарларына, аудиторларына, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 24.04.2018 №281, 14.06.2018 №481, 17.10.2018 №940, 29.12.2018 №1320, 17.11.2021 №1087, 13.12.2021 №1222, 17.09.2022 №1015, 30.04.2024 №290 үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Әтнә район Советы **карар итте:**

1. Әтнә район Советының 2022 елның 29 мартында 120 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмә”гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1нче пункта “12688” саннарын «13323» саннары белән алмаштырырга;

1.2. III бүлекнең 4нче пункты 4.6 нчы пунктчасындагы «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләре белән алыштырырга;

1.3.VI бүлекнең 1нче пункты 6нчы пунктчасындагы «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алыштырырга;

1.4. күрсәтелгән карарның 2 һәм 3 нче кушымталарын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымталар).

2. Әлеге үзгәрешләр 2024 елның 01 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында: http://atnya.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен Әтнә муниципаль районының финанс-бюджет палатасы Рәисенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
Әтнә район Советы рәисе: Г.Г.Хәкимов

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы 29.03.2022 елгы 120 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әтнә район Советы «__»_________2024 №____ карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә башлыкларын, депутатларын, сайланулы вазыйфаи затларын, нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә даими ашыручы, Контроль-хисап палатасы Рәисе, айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаларның исемнәре | Коэффициент |
|---|---|
| | 8 нче группа |
| 1 | 2 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 35272 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 31745 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 31745 |

3 нче кушымта
Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы 29.03.2022 елгы 120 номерына (Татарстан Республикасы Әтнә район Советы «__» _________2024 №____ карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә башлыкларын, депутатларын, сайланулы вазыйфаи затларын, нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә даими ашыручы, Контроль-хисап палатасы Рәисе, айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаларның исемнәре | Айлык акчалата бүләкләү күләме, сум | |
|---|---|---|
| | Унберенче группа | Уникенче группа |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 19991 | 18260 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 14366 | 13324 |
| Депутат | 13323 | 13323 |
| Җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы | 13323 | 13323 |